| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 17 декабре Иске Куак № 29

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елга бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләмен 2 873 730 сум итеп;

2) «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының фаразланыла торган гомуми күләмен 2 873 730 сум итеп;

3) «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын 0 сум итеп.

2. 2023 һәм 2024 еллар план чорына «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының 2023 елга фаразланыла торган керемнәрнең гомуми күләме 2 842 290 сум һәм 2024 елга 2 839 060 сум күләмендә булыр дип фаразлана;

2) 2023 елга «Иске Куак авыл җирлеге» бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2 842 290 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 68 370 сум һәм 2024 елга 2 839 060 сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 136 400 сум күләмендә;

3) Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге бюджеты кытлыгын - 2023 елга 0 мең сум һәм 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. 2023 елның 1 гыйнварына расларга:

«Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эчке бурычының иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге

муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга;

5. 2024 елның 1 гыйнварына расларга:

«Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эчке бурычының иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга;

6. 2025 елның 1 гыйнварына расларга:

«Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эчке бурычының иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга;

7. «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

8. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

9. «Иске Куак авыл җирлеге» бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

10. «Иске Куак авыл җирлеге» бюджетының 2022 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә 0 сум, 2023 елга 0 сум һәм 2024 елга 0 сум күләмендә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

11. Авыл җирлеге халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итүне оештыру өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү өчен 2022 елга 639 400 сум, 2023 елга 643 000 сум һәм 2024 елга 646 800 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетына әлеге пунктта каралган башка бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән башкарыла.

12. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, 2022 елга (муниципаль учреждениеләрне карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә) 783 730 сум күләмендә һәм 2023, 2024 еллар план чорына 738 190 сум һәм 720 000 сум күләмендә субсидияләр күләмен расларга.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетына әлеге пунктта каралган башка бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән башкарыла.

13. «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан 2022 елда 142 410 сум, 2023 елның план чорына 115 300 сум һәм 2024 елга 119 060 сум күләмендә бюджетара трансфертлар расларга, шул исәптән:

- 2022 елда җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 38 610 сум, план чорына 2023 елда 8 000 сум һәм 2024 елга 7 900 сум күләмендә дотацияләр;

- 2022 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга 103 800 сум, план чорына 2023 елга 107 300 сум һәм 2024 елга 111 160 сум күләмендә субвенцияләр.

14. Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең саны артуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, мондый карарларны «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына яңа функцияләр һәм вәкаләтләр бирү белән бәйле рәвештә кабул итү очракларыннан тыш.

15.Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Лениногорск районы һәм Лениногорск шәһәре территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

16. «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларының 2022 елның 1 гыйнварына «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә калдыгы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2022 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

17. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы,7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

18. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н. Сушкова